ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карап бетерелмәгән закон проектлары һәм норматив хокукый актлар проектлары буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитетларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетын закон проектлары белән эшләгәндә әлеге карарга кушып бирелгән 1 нче исемлек нигезендә җаваплы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетын закон проектлары белән эшләгәндә әлеге карарга кушып бирелгән 2 нче исемлек нигезендә җаваплы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетын закон проектлары белән эшләгәндә әлеге карарга кушып бирелгән 3 нче исемлек нигезендә җаваплы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетын закон проектлары белән эшләгәндә әлеге карарга кушып бирелгән 4 нче исемлек нигезендә җаваплы итеп билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетын закон проектлары белән эшләгәндә әлеге карарга кушып бирелгән 5 нче исемлек нигезендә җаваплы итеп билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетын закон проектлары белән эшләгәндә әлеге карарга кушып бирелгән 6 нчы исемлек нигезендә җаваплы итеп билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетын закон проектлары белән эшләгәндә әлеге карарга кушып бирелгән 7 нче исемлек нигезендә җаваплы итеп билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетын закон проектлары белән эшләгәндә әлеге карарга кушып бирелгән 8 нче исемлек нигезендә җаваплы итеп билгеләргә.

9. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта кабул ителгән закон проектына төзәтмәләр 2019 елның 10 октябреннән дә соңга калмыйча кертелә дип билгеләргә. Закон проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитетына кертелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитеты әлеге закон проектын, кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, 2019 елның 25 октябреннән дә соңга калмыйча эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга тәкъдим итәргә тиеш.

10. Әлеге карарның 1 – 8 пунктларында күрсәтелгән исемлекләргә кертелмәгән Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравыннан төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 20 сентябре
№ 37-VI ДС

1 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты**

| № | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| **Татарстан Республикасы законнары проектлары** | | |
| 1. | «Хезмәт даны шәһәре» Татарстан Республикасы мактаулы исеме турында» 163-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 2. | «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында» һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 304-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында | Алдан каралуда тора |
| 3. | «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 493-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында | Алдан каралуда тора |
| 4. | «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 614-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында | Алдан каралуда тора |
| 5. | «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 619-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында | Алдан каралуда тора |

| | | |
|---|---|---|
| **Федераль закон проекты** | | |
| 1. | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 61ПЗ номерлы федераль закон проекты | Алдан каралуда тора |

2 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты**

| № | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | **Татарстан Республикасы законнары проектлары** | |
| 1. | «Татарстан Республикасында инвестиция салым түләве турында» 605-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 2. | «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 607-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 3. | «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 608-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 4. | «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 609-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында | Алдан каралуда тора |
| 5. | «2017 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» 616-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 613-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 7. | «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 618-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| **Федераль закон проекты** | | |
| 1. | «Россия Федерациясе Салым кодексының 171, 265 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты (салым базасында иганә эшчәнлегенә чыгымнарны кабул итү режимын билгеләү өлешендә) (2019 елның 21 феврале, № вн-1081) | Алдан каралуда тора |

3 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты**

| № | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | **Татарстан Республикасы законнары проектлары** | |
| 1. | «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 236-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 2. | «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 394-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 3. | «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 606-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |

4 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты**

| № | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | **Татарстан Республикасы законнары проектлары** | |
| 1. | «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 576-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 2. | «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 615-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты**

| № | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | **Татарстан Республикасы законнары проектлары** | |
| 1. | «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 214-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 2. | «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 571-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында | Алдан каралуда тора |
| | **Федераль закон проекты** | |
| 1. | «Россия Федерациясе Су кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты (2016 елның 18 мае, № 6225) | Алдан каралуда тора |

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты**

| № | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | **Татарстан Республикасы законы проекты** | |
| 1. | «Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 610-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 2. | «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 621-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| | **Федераль закон проекты** | |
| 1. | «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 43ПЗ номерлы федераль закон проекты | Алдан каралуда тора |

7 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Социаль сәясәт комитеты**

| № | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| **Татарстан Республикасы законы проекты** | | |
| 1. | «Сугыш чоры балаларына дәүләт социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 552-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 2. | «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2020 елга пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында» 617-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |

8 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты**

| № | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | **Татарстан Республикасы законнары проектлары** | |
| 1. | «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 601-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | 1 укылышта кабул ителде |
| 2. | «2020 елга Татарстан Республикасында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 611-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |
| 3. | «2020 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 612-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан каралуда тора |

| | | |
|---|---|---|
| **Федераль закон проекты** | | |
| 1. | «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә архив эше турында» Федераль законның 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 46ПЗ номерлы федераль закон проекты | Алдан каралуда тора |